**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

**егерме сигезенче утырыш**
**КАРАРЫ**

14 июнь 2019 ел **№ 174** Теләче авылы

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны саклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы 2012 елның 13 гыйнварындагы 9 санлы Татарстан Республикасы Законын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 февралендәге «Татарстан Республикасында хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын тәртипкә салу тәртибен раслау турында»гы 126 санлы карарын Теләче муниципаль районында тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшинның 2019 елның 6 апрелендә чыккан 01-1859 санлы тәкъдимен караганнан соң, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45 санлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны саклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы 2012 елның 13 гыйнварындагы 9 санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе И. Т. Һадиев докладын игътибарга алырга.
2. Теләче муниципаль районы башкарма комитетына авыл җирлекләре башлыклары белән берлектә йорт хайваннарын тоту буенча халык белән даими аңлату эшләре алып барырга.
3. Район ветеринария хезмәтенә вакытында диагностик тикшеренүләр, профилактика вакцинацияләре һәм дәвалау-профилактика эшкәртүләре үткәрергә, шулай ук даими рәвештә клиник карап чыгуны, консультацияләр һәм хайваннарны дәвалауны гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибен саклау һәм депутат этикасы буенча комитетка йөкләргә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы И. Ф. Зарипов